| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.10.2022 с.Старое Дрожжаное № 507

2023 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристик-туган якны өйрәнү, экология-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм күп профильле белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарын кушымта нигезендә;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.А. Халитовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның "05" октябрь 507
номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать һәм эстетик | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |